# АВТОРДАН

Еш кына сыңар бер сүз документтан да күбрәк сөйли.

*Эрик Хобсбаум,*
*Британия тарихчысы*

Бу сүзлек төрле дини төшенчәләрне, аларның язылыш вариантларын, мәгънәләрен, милләт һәм дин тарихына кагылган әһәмиятле һәм кызыклы фактларны, тормышта эз калдырган күренекле затлар турындагы мәгълүматларны күп еллар буена көндәлек эш өчен теркәп барган дәфтәрләрдән, аерым кәгазьләрдән һәм картотекадан башланып китте. Картотекага Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин, Әхмәтһади Атласи, Нәкый Исәнбәт, Фатих Әмирхан, Гаяз Исхакый һ. б. күренекле шәхесләребезнең игътибарны җәлеп итәрлек фикерләре, Совет чоры китапларыннан сөрелгән хикмәтле сүзләре дә теркәлә барган иде. Тора-бара андый язмалар күбәеп, алардан файдалану кыенлашкач, тупланган төшенчәләрне, төрле гыйбарәләрне һәм Совет хакимияте елларында онытыла төшкән канатлы сүзләребезне бер җепкә тезеп тәртипкә салырга керешкәндә, бәхеткә каршы, илгә компьютерлар үтеп керде, компьютерлашу чоры башланды. Әгәр берничә техник хезмәткәр эшен алмаштырган компьютер булмаса, ихтимал, мондый күләмле эшне ялгыз гына ерып та чыга алмаган булыр идек (ә тарихи чыганакларда телгә алынган шәхесләребезнең шактый бай картотекасын (исемлеген) кирәксезгә чыгарып, юк итеп ташлавым ялгыш эш булган), чөнки, әйтик, С. Б. Веселовскийның «Ономастикон» (М., «Наука», 1974) кебек китабы да укучыларга мул мәгълүмат бирә ала. Ашыкканмын.

Әйтелгәннәрдән күренгәнчә, сүзлегебез үзенең колачы һәм эчтәлеге белән гамәлдә йөри торган күпчелек сүзлек һәм белешмәләрдән аерыла. Асылда, анда төрле характердагы, төрле юнәлештәге төшенчәләр бергә тупланган, һәм мин мондый тарихи синтезда гайре табигый нәрсә күрмим, киресенчә, кристаллаша торгач, ул яңа сыйфатларга ия булган эретмә, ягъни

 бербөтен тәшкил итте, татарның милли космосын киңрәк һәм панорамалы итеп ача торган китап туды дип уйлыйм.

Сүзлегебез практик максатларны күздә тота, хәзерге заман татар укучысын – гади укучыны – язма чыганакларга, тарихыбызга һәм иманыбызга якынайтуны, артык вакыт сарыф итмичә генә күпчелек тарихи, дини, фәлсәфи әдәбиятны зиһенгә алу эшен җиңеләйтүне максат итеп куя. Шушы күзлектән караганда, ул «Татар Ренессансы»на хезмәт итәр дип өметләнәм.

Мин баштарак сүзлекне «Кырык бакча» дип тә атамакчы булган идем, ләкин «Кырык бакча» исеме кадимирәк, дәрәҗәсезрәк, фәннилектән ерак булып тоелырга мөмкин. «Милли хәтер» исеме турында да уйладым. Дөрес, ахырда мин бу исемгә дә тукталасы итмәдем, хәлбуки анысы белешмәлекнең характерын һәм колачын төгәлрәк чагылдыра. Ә тирәнлеккә килгәндә, объектив укучы сүзлегебездә бүгенге көн югарылыгыннан торып язылган һәм чор таләпләренә җавап бирерлек хөр фикерле мәкаләләрне яки сайлап алынган үлемсез цитаталарны күрми калмас дип уйлыйм.

Сүзлектә дини философия игътибар үзәгендә тора. Минем аңлавымча, кеше аңын формалаштыруда Тел һәм Дин (Гыйлем) төп рольне уйнаганнар. Фикерләүче кешене (адәми затны) хезмәт тудырмаган, беренче нәүбәттә Тел тудырган (бу фикер яңа түгел).

А. Солженицын үзе төзегән «Русский словарь языкового расширения» сүзлегендә «Телне баетуның иң әйбәт ысулы – электә тупланган, ә аннары җуелган байлыкларны кайтару» дигән фикерне алга сөргән иде. Безнең сүзлегебез – татар дөньясында бу юнәлештәге тәүге адымнарның берсе. Ул онытылган сүзләребезнең кулланылыш үрнәкләрен һәм чикләрен күләмле генә мисал-иллюстрацияләрдә күрсәтеп, аларны тергезергә тырыша (*ак киек* – пушной зверь; *аламан* – отряд; *алык* – хан заманында халыктан җыеп алына торган салым, җыем, алык-салык, *алман, тартынак*; *артыл* – хан сакчылары, ярдәмче гаскәр, арьергард (хәзерге телдә – *әртил*); *аю сөңгесе* – аю аулаганда кулланыла торган бер (яки ике) җәпле сөңге (керәшә), рогатина; *әшкярә* – ачык (апачык, аермачык), күз алдында, яшермәстән, русча – *гласно*; *багавыл* – караучы, химаяче, опекун, авыл башы (бәк авыл); *беркетелмешләр* – крепостнойлар, чура-коллар; *бозгын божра* – логикада ялгыш (бозгын) дәлилләү, русча – *порочный круг*; *боктырма* – яшеренгән гаскәр, поскак, засада; *бола* – чуалыш, фетнә, гыйсъян; *болачылар* – фетнәчеләр; *бөркетлек, боркытлык* – капище; *буралгы* – сукбай, русча – *бродяга*. Ихтимал, *бурлак* сүзе дә шушы *буралгы* сүзенә барып тоташа булыр; *бурган би* – шаман, кам. Сүзлеккә теркәлгән мондый сүзләр

байтак, аларның саны, ихтимал, берничә йөздән ашып китәдер). Бу яктан караганда, сүзлектә төрки асылга кайтырга, гомумтөрки һәм уртак сүз тамырларын эшкә җигәргә омтылыш та сизелә торгандыр дип уйлыйм.

Татар телендә һәм, гомумән, төрки телләрдә сан (бер, ике, өч һ. б.) атамаларының мәгънәләре һәм килеп чыгышы турында төрле чыганаклар нигезендә язылган материалларда да күпләр үзләре өчен яңалык табар.

*Сабантуй, Сөннәтләү, Җомга, Үлем* һ. б. гомумбилгеле төшенчәләрне яктыртканда да, искене кабатламаска, яңарак материалларга таянырга тырыштык.

Игътибарлы укучы төрле авторлардан алынган мисал-иллюстрация һәм өзекләрнең билгеле бер идеологик юнәлештә тезелүен, фикрияти система тәшкил итүен, гадәттә, уйлануларга этәрүен дә күрми калмастыр. Бу яктан ул татар өчен мәшһүр саналган «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»нә төрле объектив сәбәпләр аркасында керми (кертелми) калган сүзләрне дә колачларга омтыла. Тәкъдим ителә торган сүзлегебез татар телендәге шәрык алынмалары сүзлеген алмаштыра алмаса да, аңа, «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»нә теркәлүләренә дә карамастан, шул заманның кырыс таләпләре аркасында дини-фәлсәфи мәгънәсе ачылмый калган лексик берәмлекләр дә кертелде. Фикергә басым ясау кирәк булган очракларда, теге яки бу сүз кулланылган тәрҗемә текстларга да таянылды. Бу мисаллар сүз яки төшенчәнең төрле *мәгънә төсмерләрен* дә ачалар (аларны сыңар мисалда гына ачып бетерү мөмкин түгел).

Аннары «Русча-татарча-гарәпчә алынмалар сүзлеге»ндә алынма сүз дип үк аталырга «хаклары житенкерәмәгән» берәмлекләр дә очрый. «Миллият сүзлеге»нә без андый окказиональ һәм сирәк сүзләрне теркәмәскә тырыштык, ләкин моны бәяләүдә субъективлыктан котылып булмавын да онытмаска кирәк.

Гарәби алынма сүзләрнең мәгънәләрен аларның логик үсеше тәртибендә бирергә тырыштык, ләкин аерым очракларда фәлсәфи мәгънә алга чыгарылды.

Сүз һәм төшенчәләргә, аларның кулланылышына мисаллар китергәндә, ул мисалларның беренче нәүбәттә фикри кыйммәтенә, оригинальлегенә, тулылыгына һәм бөтенлегенә игътибар итәргә тырыштык.

Шунысын да әйтик: алынмалар, нигездә, текстта очраган рәвештә (язылышта/язылышларда) кертелделәр. Шуның аркасында төзелеш ягыннан охшаш алынмаларның бердәй язылышын тәэмин итү үзе бер зур мәсьәлә булып килеп баса. Бу мәсьәләне бүген ахырынача хәл итү мөмкин түгел дип уйладым. Сүзлектә янәшәдә *инсане гали* һәм *инсани камил* кебек язылышлар очравы шушы сәбәп белән аңлатыла.

Сүзлектә Татарстан, Россия һәм чит илләрдәге байтак кына тарихи һәм хәзерге мәчетләр, мәдрәсәләр турында кыскача мәгълүмат бирелде. Әлбәттә, аларның Татарстанда булганнарын гына да теркәп бетерү мөмкин түгел, өстәвенә аларның саны үзгәреп тора. Һәрхәлдә, монысы – киләчәк эше.

Сүзлектә милләт тарихында эз калдырган, ләкин хәзергә кадәр нәшер ителгән белешмәләргә теркәлмәгән шәхесләр күз уңында торды. Шул ук вакытта, гадәттә, тискәре бәяләнә торган шәхесләр турында да мәгълүмат теркәлде, чөнки еш кына аларның биографияләре һәм кылган гамәлләре чорны аеруча калку итеп чагылдыра (мәс., Ишми ишан, Шкафчы Әхмәтҗан, Һинди Минһаҗ, Мәмлиев Төхфәтулла, Мирсәед Юнысов, Вагыйз Нәүрузи, Борһан Шәһиди һ. б. турындагы материаллар).

Сүзлек Коръәнне татарчага тәрҗемә итүгә нисбәтле мәсьәләләрне игътибар үзәгендә тота, чөнки хәзерге вакытта, Изге китапның татарчага күп санлы тәрҗемәләре нәшер ителгән бер чорда, тәрҗемәнең пөхтәлеген тәэмин итү өчен, ныклы әзерлек кирәклеген онытып җибәргәлиләр. Шуларны истә тотып, сүзлектә сүрәләрнең төрле тәрҗемәләрдәге атамаларын һәм, гомумән, Коръәни терминологияне чагыштыру мәгъкуль күрелде.

Игътибарлы укучы сүзлектә суфичылыкка аеруча зур игътибар бирелгәнлеген дә күрми калмастыр. Моның сәбәбе бер генә: ислам философиясе суфичылыкта иң югары дәрәҗәсенә күтәрелә, һәм нәкъ менә суфи әдәбиятта бүгенге позитив (иҗаби) фән әле генә ирешеп килгән хакыйкатьләргә һәм даһиларча алдан күрүләргә, пәйгамбәрлек үрнәкләренә тап буласың. Кызганычка каршы, безнең җирлектә Совет хакимияте беренче чиратта нәкъ менә фикер ияләрен, – димәк, тарикать әһелләрен юк итү кирәклеген аңлап эш иткән...

Күп кенә очракларда, тарихи ачыклык кертү йөзеннән, Казан шәһәрендәге урам исемнәрен (искеләрен һәм яңаларын), табигать ядкярләрен, шулай ук аерым микротопонимнарны да теркәү мәгъкуль күрелде, чөнки алар да безнең милли космосыбызга карыйлар. Язылышны унификацияләү өчен дә моның әһәмияте булыр дип өметләник. (Яңа исемнәр кушу һәм искеләрен кайтару сәясәте артыннан өлгерү җиңел түгел, кайбер үзгәрешләр игътибарымнан читтә калган булса – гафу үтенәм.)

Чыннан да, ихтимал, сүзлегебезнең язылыштагы чуарлыкны бетерүгә дә азмы-күпме файдасы тияр. Орфографиябездәге төрлелек бер бүген генә башланган кимчелек түгел. Галимнәр язылыштагы дикъкатьсезлекнең борынгы чыганакларда (мәс., Сәедгәрәй хан ярлыгында) шактый еш күзәтелүен искәртәләр. XIX гасырда ук күренекле мөстәшрикъ һәм Казанда татар китаплары цензоры И. Н. Березин татарларның сүз язылышына игътибар бирмәүләреннән һәм шуның аркасында текстларны дөрес укырга уңайсыз булуыннан зарлана. Бүгенге һәм фәнни, һәм популяр әдәбиятта, хәтта сүзлек-белешмәләрдә дә, бигрәк тә алынма сүзләрнең танымаслык дәрәҗәдә үзгәртеп язылуына тап буласың. Хәтта, әгәр Березин әфәнде бүгенге китапларыбызны

күрсә, татарның язу культурасы бер дә алга китмәгән икән дип уйлап куяр иде сыман. Соңгы елларда күпләп нәшер ителә башлаган дини китапларыбызда бу кимчелек аеруча күзгә ташлана. Хәтта пәйгамбәрләр исеменең язылышы да тотрыксыз, сүрә исемнәрен язуда да чуарлык хөкем сөрә. Мондый чуарлыктан телебезнең үзенчәлекләре өчен яраклы латин хуруфатына күчкәч кенә котылып булыр шикелле, ләкин бу юнәлештә хәзер үк эшләргә кирәк. Мин, һич югында, төрле вариантларны бергә туплап, аларны чагыштырырга, бәяләргә һәм аларга мөнәсәбәтемне белдерергә тырыштым.

Исем-фамилияләрне язудагы чуарлык тормышның үзеннән үк килә. Бу бигрәк тә гарәби чыгышлы исемнәргә карый. Мәс., татарда еш очрый торган *Хәбибрахман* исеменең башка телләрдәге чыганакларда *Хәбиб-әр-Рахман, Хәбибар-Рахман, Хәбибур-Рахман, Хәбиб ур-Рахман, Хәбиб әл-Рахман, Хәбибәррахман, Хәбибуррахман, Хәбиб ул-Рахман, Хәбиб-ул-Рахман* кебек язылышлары очрый. Гарәп исемнәренең язылышын унификацияләү – үзе бер зур мәсьәлә, ул мәсьәлә бер татар теленә генә кагылмый һәм, һәрхәлдә, аны бер селтәнүдә генә хәл итү мөмкин түгел.

Рус теле калыбында ясалган фамилияләребезне (исемнәребезне) ничек язу мәсьәләсе дә вакыт-вакыт кузгалып тора. Мәс., *Мәхмүтов* дип язаргамы, әллә *Мәхмүтев* дипме? *Давыдов* дөресме, әллә *Даутов*мы? Хәтта фамилиядәге *-ов, -ев* кушымчаларын Көнбатыштагычарак *-оф, -еф* формасына күчерү турында да сүз алып барырга бик мөмкин.

Дәүләт күләмендә генә хәл ителергә тиешле барлык бу мәсьәләләрне хәзергә әйләнеп узарга туры килә.

Аерым очракларда, кулъязма хәлендә сакланган борынгы сүзлекләргә мөрәҗәгать итеп, алардан да файдаландык. Мәс., *мәгълүмләү* (игълан итү, халыкка белдерү, публикация) сүзе Казан университетының Фәнни китапханәсендә саклана торган кулъязма сүзлектән алынган.

Әлбәттә, сүзлегебез гадәти энциклопедияләрне алмаштыра алмас, ләкин кайбер мәсьәләләрдә коры энциклопедия мәгълүматларын тулыландырырга да мөмкин. Укучы сүзлегебездә еш кына «көтелмәгән информация»гә дә тап булып, ул мәгълүмат төшенчәне (теманы, сюжетны) өстәмә рәвештә ачыклый алса яки теге яки бу фактны истә калдырырга ярдәм итсә, укучыны бик билгеле сыман тоелган нәрсәләргә (сүзләргә, күренешләргә) игътибар беләнрәк карарга һәм алардагы нечкәлекләрне тотып ала белергә өйрәтсә, бигрәк тә канәгать булыр идек.

Аерым очракларда теге яки бу теманы аеруча тулы һәм оригиналь итеп яктырткан текстларны русча чыганактан турыдан-туры тәрҗемә итеп бирүне кулайрак күрдек (мәс., *Төркиләр ислам тарихында, Сарк әш-шигырь* кебек материаллар). Мондый «алынмалар» бер-ике дистәдән артмаса кирәк. Укучы материалның кайсы чыганактан алынуы турында башта ук кисәтелә, чөнки «ят» текст (бигрәк тә Көнбатыш авторларыныкы булганда) еш кына терминологик үзенчәлекләре белән үк аерылып тора һәм укучыны җәлеп итә ала дип уйлыйм.

Мәгълүм ки, сүзлек кебек гавәми чыганаклар, гадәттә, «куян шулпасының шулпасы» гына булып чыгалар. Ләкин автор, ошбу сүзлекне актарганда, укучылар чын, беренчел ризыктан да авыз итәрләр дип өметләнә.

Сүзлекнең камиллегенә килгәндә, без аның әлегә тулылыктан шактый ерак торуын бик яхшы аңлыйбыз һәм шуңа күрә аны баштарак «Дини-тарихи аңлатмалы сүзлек өчен материаллар» дип атаган идек. Шулай да киләчәктә сүзлекнең лөгатьлеген тагы да тулыландыру һәм төзекләндерү күздә тотыла. Мәсәлән, сүзлектә сугыш киемнәре темасын тиешенчә ачарга, аларны классификацияләргә һәм тасвир итәргә әлегә мөмкинлек булмады. Казандагы һәм, гомумән, Татарстандагы чиркәү-монастырьларны теркәү юнәлешендә дә эшлисе бар иде, чөнки бу объектлар Казан шәһәренең, әйтик, тарихи географиясен һәм топографиясен, урам-тыкрыкларның урыннарын ачыкларга ярдәм итә. Кайчагында рус чиркәве татар мәчете өстенә салынган яки мәчет бинасыннан үзгәртеп төзелгән, чиркәү төзегәндә, еш кына борынгы татар гыйммраннарының таш-кирпече яки хәтта изге кабер ташлары файдаланылган булып чыга.

Киләчәктә, әлбәттә, мәкаләләрне бердәйләштерүгә дә, тарихи даталарны ачыклауга да, персоналияләр исемлеген киңәйтүгә дә ныграк игътибар ителер, тик шунысы хак: мәкаләләрдәге шәхси төсмерләрне, үзенә бертөрле «кыр чәчәкләре»н, үткәнебезне сагыну яки сагыш кебегрәк ностальгия хисләрен дә саклап каласым килде.

Сүзлекнең ахырында бирелгән әдәбият исемлеге файдаланылган һәм мөрәҗәгать ителгән барлык чыганакларны да колачлап бетерми. Анда күрсәтелгәннәрдән тыш, мин күп санлы (нигездә, рус телендәге) энциклопедияләргә һәм йөзләгән татарча газета-журнал мәкаләләренә дә таяндым. Шунысы куанычлы: сүзлектә урын алган күпчелек темаларга үзебезнең татар һәм мөселман авторларыннан матур-матур өзекләр, канатлы сүзләр һәм хикмәтләр табарга мөмкин икән. Юк, милләтебез төшеп калганнардан түгел, халкыбызда фикер ияләре, чын гыйлем әһелләре җитәрлек (булган һәм бар), ә төркилеген гасырлар буена саклап кала алган телебез иң нечкә һәм «гали материяләр» турында да фикер йөртергә мөмкинлек бирә икән.

Сирәк очракларда «Шан кызы дастаны» кебек тарихилыгы «ике сарылы» булган мифологик чыганакларга да мөрәҗәгать ителде, чөнки алар да, мәгълүм дәрәҗәдә, билгеле, яңа эзләнүләргә этәрәләр. Мәсәлән, «Шан

кызы дастаны»на (Микаил-Башту ибн Шамс Тәбир, Әнкара, 1991) кушымта рәвешендә бирелгән сүзлекчәдәге борынгы болгар тәңреләренең исемлеген безгә башка чыганаклардан билгеле булган реестр белән чагыштыру да җимеш бирергә мөмкин. Ә китапның чынлыгына килгәндә, бу сүзлекнең авторы аны бик яшьли вафат булган И. М. Нигъмәтуллин тарафыннан язылган тарихи *фэнтези* кебегрәк кабул итә. Бик ихтимал, шушы хыялый, хәтта әкияти әсәре аркасында Нигъмәтуллинның исеме мәңгелеккә тарихка кереп калыр, ә аны (дөресрәге, аның хезмәтен) аты-юлы белән сүгүче бүгенге дәрәҗәле һәм бик үк дәрәҗәле дә булмаган галим-голяманың күбесе тәмам онытылыр әле... Әлеге сирриятле автор, ни өчендер, белмим, Такташның «Киләчәктән хатлар»ындагы әллә каян пәйда булган серле һәм аңлаешсыз Нигъмәтуллинны искә төшерә...

Фальсификация дип уйланыла торган «Җәгъфәр тарихы»нда Казан мәчетләре турында китерелгән кайбер мәгълүматларны да гипотеза тәртибендә кабул итәргә ярый дип уйлыйм.

«Җәгъфәр тарихы»нда телгә алынган затларның характеристикасы башлыча И. Р. Мусинаның «История Древней Руси в булгарских летописях Бахши Имана «Джахфар тарихы» дигән хезмәтеннән алынды (Йордан Табовның болгарчадан тәрҗемә ителгән «Когда крестилась Киевская Русь» китабына кушымта). И. Р. Мусина «Җәгъфәр тарихы»нда телгә алынган фактларны һәм шәхесләрне рус елъязмалары һәм башка чыганаклар белән чагыштыра һәм, минем карашымча, кызыклы гына нәтиҗәләр чыгара.

Ошбу сүзлегебездә И. Р. Мусина туплаган материалларга да беркадәр игътибар итәргә тырышылды. Шулай ук Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Мөслиминең «Тәварихы Болгария» («Болгар тарихы») китабында да дөреслеккә туры килә торган фактларны табарга була. Олжас (Улҗас) Сөләймановның «Аз и Я», Морад Аджиның «Европа, тюрки, Великая степь» һ. б. китапларына карата да шуны ук әйтә алам. Сирәк-мирәк кенә булса да, Г. В. Носовский белән А. Т. Фоменколарның «Яңа хронология» гипотезасына нигезләнгән хезмәтләренә мөрәҗәгать иттем, чөнки аларның аерым фикерләре тарихчыларны аптыраштa калдыра торган сорауларга җавап бирә дип уйлыйм (мәс., Куликово кырында – И. Р. Мусина аны «Һәлак кыры» дип атый – мәшһүр сугышта һәлак булган күп меңнәрчә корбаннарның бер генә сөяге дә табылганы юк, һәм Куликово кырын аркылыга-буйга казып чыккан археологлар бу фактны берничек тә аңлата алмыйлар, әлеге авторлар исә моңа һич тә көтелмәгән җавап тапканнар кебек). Шулай да Фоменко һәм Носовскийларның Шәрык чыганаклары белән җитәрлек эшләмәүләре күзгә ташлана. Авторлар Дмитрий Донской заманында һәм аннан соң да сугылган рус акчаларында гарәп шрифтындагы язулар барысы да гарәп телендә дип уйлаулары белән ялгышалар, чөнки бу язулар, гадәттә, саф татар телендә (мәс., «Ибан Москов акчасы будыр»). Әлеге авторларның «Яңа хронология»се белән ислами хронологиянең ярашмавын инде әйтеп тә тормыйбыз. Шәрык чыганакларыннан хәбәрдар булмау кебек кимчелек, мәсәлән, В. Макаренконың «Ключи к дешифровке истории Древней Европы и Азии» (М., «Вече», 2005) китабына аеруча хас. Соңгы елларда чыккан бихисап русофил хезмәтләрдә рус тарихын башыннан ахырына кадәр данлыклауга, рус милләтен башка барлык халыклардан өстен, Алла тарафыннан сайланмыш кавем итеп күрсәтергә омтылыш ята. Мин андый «чыганак»ларны игътибарсыз калдырдым һәм ялгышмадым дип уйлыйм. Һәрхәлдә, мондый шөбһәле яки бәхәс уятырлык очракларда мин чыганакны атап күрсәтәм һәм укучыбызның сәламәт, тәнкыйди акылына исәп тотам.

## Сүзлектә сүзләрнең бирелеше турында бер-ике сүз

Сүрәнең исеме янында җәя эчендә бирелгән сан сүрәнең Коръәндәге тәртип номерын күрсәтә.

Коръән сүрәләренә юнәлткәндә, сүрә һәм аять номерлары гадәти гарәп цифрлары белән бирелде. Мәс., (3:152/145–175/169) Коръәндәге өченче сүрәнең 152 нчедән алып 145 нчегә кадәр аятьләре һәм 175 нчедән алып 169 нчы аятьләренә кадәр дигән сүз. Аять номерларында әүвәл бездә кабул ителгән нумерация күрсәтелде.

Коръән сүрәләрен кайчан һәм ничә тапкыр уку файдалы һәм фазыйләтле булуы турындагы гамәли киңәштәкъдим-рекомендацияләр башлыча «Коръән-Кәрим» китабыннан алынды (төзүчесе – Фәрид хәзрәт Сәлман). Аларның күбесен аутотренинг кысаларында аңлатырга һәм нигезләргә мөмкин. Теге яки бу сүрәне ничә тапкыр (3, 7, 10, 18, 21, 40, 41, 70, 71, 100, 180, 1000 яки 40 мең тапкыр) кабатлау турында санлы күрсәтмәләр үзләре дә, игътибарны җәлеп итеп, сораулар тудыралар.

Төрки телләрдәге байтак кына мисал-иллюстрацияләр Ә. Н. Нәҗипнең «Историко-сравнительный словарь тюркских языков XIV века» дигән хезмәтеннән (1 нче китап) алынды (бу очракта авторлары яки төп чыганак күрсәтелмәгән). Транскрипция үземнеке (ул бүгенге татар язылышына якынайтылган).

Квадрат җәяләр эченә автор текстына өстәмә яки аңлатма сүзләр урнаштырылды.

Аңлатма өлешендәге куш авыш сызыклар («параллелькалар») иллюстрация өчен китерелгән һәм курсив белән җыелган мисалларны, сүзнең кулланылыш үрнәкләрен, тотрыклы сүз тезмәләрен һ. б. ны аеру өчен куелды. Сүзнең берничә мәгънәсе булган очракларда, кагыйдә буларак, һәр мәгънә өчен аерым куш сызыклар хезмәт итә.

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТУЛАР ҺӘМ АББРЕВИАТУРАЛАР

A.D. – Anno Domini («Алла елы» мәгънәсендә) Миляди ел. Рус әдәбиятындагы Р.Х. (Рождество Христова)га тәңгәл
*б. э. к. (я. э. к.)* – безнең эрага кадәр (яңа эрага кадәр)
*бор.* – борынгы
*бор.т.* – борынгы татарча
*бор.төр.* – борынгы төрки
*вә илх.* – һәм башкалар (һ. б.); «Ила ахири»дан кыскартып *илх.* сүзе ясалган
*г.* – гарәпчә
*гр.* – гарәпчә-русча
*гт.* – гарәпчә-татарча
*грек.* – грекча
*г.с., г-с* – галәйһиссәлам
*гф.* – гарәпчә-фарсыча
*гфт.* – гарәпчә-фарсыча-татарча
*диал.* – диалекталь
*иск.* – искергән
*к.* – казахча
*кер.* – керәшеннәрдә
*кыт.төрк.* – кытайча-төркичә
*м.* – миляди
*мәс.* – мәсәлән
*монг.* – монголча
*неол.* – неологизм
P.S. – постскриптум
*р.* – русча (һәм Көнбатыш телләре)
*р.а.г.* һәм *р.а.* – разый Аллаһу ганһу
*рф.* – русча-фарсыча
*с.г.в.* – саллаллаһу галәйһи вәссәлам
*с.г.с.в.* – салаллаһу галәйһиссаләтү вәссәлам
*т.* – татарча
*төр.* – төрекчә
*тар.* – тарихи
*тф.* – татарча-фарсыча
*ф.* – фарсыча
*фг.* – фарсыча-гарәпчә
*фт.* – фарсыча-татарча
һ. – һиҗри
*һ. б.* – һәм башкалар
*чаг.* – чагыштыр

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Аа<br>Әә<br>Бб<br>Вв | Гг<br>Дд<br>Ее<br>Ёё | Жж<br>Җҗ<br>Зз<br>Ии | Йй<br>Кк<br>Лл<br>Мм | Нн<br>Ңң<br>Оо<br>Өө | Пп<br>Рр<br>Сс<br>Тт | Уу<br>Үү<br>Фф<br>Хх | Һһ<br>Цц<br>Чч<br>Шш | Щщ<br>Ъъ<br>Ыы<br>Ьь | Ээ<br>Юю<br>Яя |